**МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.03.2016 № 21-53-11

Казань ш.

Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган бюджет кредитларына банк гарантиясенең, поручительлекнең ышанычлылыгын (ликвидлыгын) бәяләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93.2 статьясындагы 3 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 49 статьясы нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган бюджет кредитларына банк гарантиясенең, поручительлекнең ышанычлылыгын (ликвидлыгын) бәяләү тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.
3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры М.Д.Фәйзерахмановка йөкләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 11.03.2016 ел, № 21-53-11 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган бюджет кредитларына банк гарантиясенең, поручительлекнең ышанычлылыгын (ликвидлыгын) бәяләү тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93.2 статьясындагы 3 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 49 статьясы нигезендә эшләнеп, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган бюджет кредитларына банк гарантиясенең, поручительлекнең ышанычлылыгы (ликвидлыгы) күрсәткечләрен билгели.

2. Банк гарантиясенең һәм поручительлекнең ышанычлылыгы банк һәм башка кредит оешмасының (алга таба – гарант) һәм поручительләрнең финанс ягыннан тотрыклылыгы белән билгеләнелә.

3. Бу Тәртип максатында банк гарантиясенең һәм поручительлекнең ышанычлылыгы (ликвидлыгы) төшенчәсе гарантның һәм поручительнең заемга алучының бюджет кредитын кире кайтару буенча бурычларын үз вакытында һәм тулы күләмендә үтәүгә сәләтен аңлата.

4. Бурычлар үтәлешен тәэмин итү югары дәрәҗәдә ликвидлыкка ия булырга тиеш. Тәэмин итү күләме бирелә торган бюджеты кредиты күләмен һәм аның буенча процентларны һәм тиешле килешүдә күздә тотылган башка түләүләрне капларлык булырга тиеш.

5. Бурычларны үтәүне тәэмин итүне рәсмиләштерү Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредиты бирелгәнче хәл ителә.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган бюджет кредитларына банк гарантиясе һәм поручительлекне бәяләүне хәл итә.

II. Банк гарантиясенең ышанычлылыгын (ликвидлылыгын) бәяләү

2.1. Бу Тәртип максатында, гарант түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

2.1.1. Гарант, “Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында” 26 октябрь, 2002 ел, № 127-ФЗ Федераль закон нигезендә, юкка чыгарылу, үзгәртеп оештырылу, эшчәнлеген туктату хәлендә булмаска, бөлгенлеккә төшүнең (банкротлык) теге яки бу стадиясендә тормаска.

2.1.2. Гарантның Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында күздә тотылган тәртиптә эшчәнлеге туктатып торылмаска.

2.1.3. Гарантның Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр

буенча, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча түләү срогы чыккан бурычы булмаска, шулай ук Татарстан Республикасы тарафыннан элегрәк бирелгән дәүләт гарантияләре буенча җайга салынмаган йөкләмәләре булмаска тиеш.

2.1.4. Гарант банк операцияләрен башкаруга Россия Федерациясе Үзәк банкының генераль лицензиясенә ия булырга тиеш.

2.1.5. Гарант, "Россия Федерациясе банкларында физик затларның кертемнәрен иминиятләштерү турында" 23 декабрь, 2003 ел, № 177-ФЗ Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе банкларында физик затларның кертемнәрен мәҗбүри иминиятләштерү системасында катнашырга тиеш (Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия банкының рәсми сайтына урнаштырылган, соңгы хисап датасына рәсми мәгълүматлар).

2.1.6. Гарантка карата Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан "Россия Федерациясенең Үзәк банкы (Россия Банкы) турында" 10 июль, 2002 ел, № 86-ФЗ Федераль закон нигезендә билгеләнгән мәҗбүри нормативларны бозган өчен йогынты чаралары куллану очраклары булмаска тиеш (Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия банкының рәсми сайтына урнаштырылган, соңгы хисап датасына рәсми мәгълүматлар).

2.2. Бу Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүче гарант Министрлыкка түбәндәге документлар тапшыра:

а) бюджет кредитын алучының (алга таба – алучы) йөкләмәләре буенча гарант булырга ризалык бирүе турында гарантның хаты;

б) гарантның гамәлгә кую документларының, дәүләт теркәвенә алу турында таныклыгының, аңа кертелгән барлык үзгәрешләрдән һәм өстәмәләрдән чыгып, нотариуста расланган күчермәләре;

в) гарант тарафыннан расланган, гарантның бердәнбер башкарма органы, башка вәкаләтле затының гарант исеменнән алыш-бирешләр ясауга һәм гарантның баш бухгалтерының вәкаләтләрен раслаган документлар (сайлап кую турында карар, билгеләү турында боерык, вазыйфага керешү турында боерык, контракт күчермәсе, ышанычнамә), шулай ук әлеге затларның имзаларының һәм гарант мөһеренең нотариуста расланган үрнәкләре;

г) гарант идарәсе вәкаләтле органының банк гарантиясен бирү (алучының бурычларын үтәүне тәэмин итү максатында) буенча алыш-бирешне хәл итүгә ризалыгын (хуплавын) раслаган документның нотариуста расланган күчермәсе;

д) Россия Федерациясе Үзәк банкының банк операцияләрен башкаруга генераль лицензиясенең нотариуста расланган күчермәсе;

е) салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча, салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча недоимканың, шулай ук бюджет средстволарыннан файдаланган өчен процентлар, пенялар, штрафлар түләү һәм башка финанс санкцияләре буенча түләү буенча бурычның булмавын раслаган, гарантның исәп-хисаплары торышы турында салым органыннан, Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан һәм Россия Федерациясе Социаль

иминиятләштерүе фонды территориаль органыннан белешмәләр;

ж) гарант тарафыннан расланган, хисап финанс елына һәм соңгы хисап датасына бухгалтерия балансы һәм табышлар һәм керемнәр турында хисап;

з) гарант тарафыннан расланган, бу Тәртипнең 2.2 пунктындагы “а” пунктчасы нигезендә, хат белән мөрәҗәгать иткән елга кадәрге елда гарантның бухгалтерия исәп-хисабының дөреслеге турында аудитор бәяләмәсе күчермәсе;

и) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнелә торган формада гарантның үз средстволары (капиталы) исәпләмәсе һәм, рөхсәт итүле күрсәткечләр диапазонын китереп, соңгы хисап датасына мәҗбүри нормативлар күрсәткечләре;

к) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнелә торган формада мәҗбүри нормативлар турында мәгълүмат;

л) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнелә торган формада гарантның активларының сыйфаты турында мәгълүмат;

м) гарант җитәкчесе имза салган һәм мөһер белән расланган, гарантның чиста активлары исәпләмәсе;

н) гарантның соңгы ярты ел дәвамында Россия Федерациясе Үзәк банкының мәҗбүри резерв таләпләрен үтәве турында, клиентларга исәп-хисап документлары буенча вакытында түләмәү фактларының юклыгы турында, гарантка Россия Федерациясе Үзәк банкы ягыннан мәҗбүри йогынты чараларының күрелмәгәнлеге турында Россия Федерациясе Үзәк банкыннан белешмә;

о) Россия Федерациясе Үзәк банкының вәкаләтле вазыйфаи затлар кандидатурасын килештерүен раслаган документлар.

Министрлык гарантны Бердәм дәүләт юридик затлар реестрына кертү фактын раслаган, шулай ук гарантның үзгәртеп кору яки юкка чыгарылу процессында торуы (тормавы) турында, гарантка карата бөлгенлеккә төшү (банкротлык) эше буенча эш кузгатылган (кузгатылмаган) булуы турында мәгълүматларны раслаган документларны Федераль салым хезмәтеннән соратып алуга хокуклы.

2.3. Гарантның финанс хәле түбәндәге күрсәткечләр ярдәмендә билгеләнә:

соңгы финанс елына һәм агымдагы елның үткән чорында зыянга эшләмәгәнлеге;

гарант активларының югары сыйфатлы булуы (I һәм II сыйфат категорияләрендәге активлары активларының гомуми күләменең ким дигәндә 50 процентын тәшкил итәргә тиеш);

гарантның Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән мәҗбүри нормативларга туры килүе;

гарантның чиста активлары күләме, бу күләм бирелә торган бюджет кредитыннан өч тапкырдан күбрәк булырга тиеш.

2.4. Министрлыкка алынган гарант документлары алынган көнне теркәлә.

2.5. Гарант тарафыннан тапшырылган документлар бу Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры килмәгән очракта, Министрлык документлар теркәлгәннән соң биш эш көненнән дә соңга

калмыйча, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, аларны гарантка кире кайтара.

2.6. Гарант тарафыннан тапшырылган документлар бу Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры килгән очракта, Министрлык аларны документлар теркәүгә алынганнан соң эш көннәрендә исәпләнелә торган 15 көн эчендә, гарантның бу Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен ачыклау һәм бу Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләрдән чыгып, аның финанс хәлен билгеләү өчен тикшерә.

Министрлык документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча банк гарантиясен алучы йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә кабул итеп алу мөмкинлеге (кабул итүдән баш тарту) турында бәяләмә әзерли, гарантка бу хакта бәяләмә әзерләнгәннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча язмача хәбәр ителә.

## III. Поручительлекнең ышанычлылыгын (ликвидлылыгын) бәяләү

3.1. Бу Тәртип максатында поручитель түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

3.1.1. Гарант, “Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында” 26 октябрь, 2002 ел, № 127-ФЗ Федераль закон нигезендә, юкка чыгарылу, үзгәртеп оештырылу, эшчәнлеген туктату хәлендә булмаска, бөлгенлеккә төшүнең (банкротлык) теге яки бу стадиясендә тормаска.

3.1.2. Гарантның Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында күздә тотылган тәртиптә эшчәнлеге туктатып торылмаска.

3.1.3. Гарантның Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча түләү срогы чыккан бурычы булмаска, шулай ук Татарстан Республикасы тарафыннан элегрәк бирелгән дәүләт гарантияләре буенча җайга салынмаган йөкләмәләре булмаска тиеш.

3.2. Бу Тәртипнең 3.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүче поручитель Министрлыкка түбәндәге документлар тапшыра:

а) алучының йөкләмәләре буенча поручитель булырга ризалык бирүе турында поручительнең хаты;

б) гамәлгә кую документларының, дәүләт теркәвенә алу турында таныклыгының, аңа кертелгән барлык үзгәрешләрдән һәм өстәмәләрдән чыгып, поручитель раслаган күчермәләре;

в) поручитель тарафыннан расланган, поручительнең бердәнбер башкарма органы, башка вәкаләтле затының поручитель исеменнән алыш-бирешләр ясауга һәм поручительнең баш бухгалтерының вәкаләтләрен раслаган документлар (сайлап кую турында карар, билгеләү турында боерык, вазыйфага керешү турында боерык, контракт күчермәсе, ышанычнамә), шулай ук әлеге затларның имзаларының һәм поручитель мөһеренең нотариуста расланган үрнәкләре;

г) поручитель идарәсе вәкаләтле органының поручительлек буенча (алучының йөкләмәләрен үтәү өчен) алыш-бирешне хәл итүгә ризалыгын (хуплавын) раслаган документның нотариуста расланган күчермәсе;

д) поручительнең хуҗалык эшчәнлеген алып баруга лицензиясенең нотариуста расланган күчермәсе (Россия Федерациясе законы нигезендә поручитель тарафыннан башкарыла торган эшчәнлекнең лицензия нигезендә хәл ителүе билгеләнгән очракта);

е) поручительнең кредит оешмаларында ачылган гамәлдәге счетлары турында салым органы тарафыннан расланган белешмә;

ж) поручительләрнең расчет счетларында средстволарның булуы турында һәм аларның картотека суммасы турында банклар тарафыннан бирелгән белешмәләр;

з) поручитель тарафыннан расланган, хисап финанс елына һәм соңгы хисап датасына бухгалтерия балансы, финанс нәтиҗәләре турында хисап, аларга аңлатма язулары белән, аларны кабул итү турында салым органы билгесе белән һәм төп средстволар турында баланс статьялары расшифровкасы белән, төгәлләнмәгән төзелеш, матди кыйммәтләргә керем алу максатында финанс салулар, озак сроклы финанс салулар, кыска сроклы финанс салулар, дебиторлык бурычы, озак сроклы йөкләмәләр, кыска сроклы кредитлар һәм заемнар, кредиторлык бурычы (бурычның һәр төре буенча) турында хисап;

и) салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча, салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча недоимканың, шулай ук бюджет средстволарыннан файдаланган өчен процентлар, пенялар, штрафлар түләү һәм башка финанс санкцияләре буенча түләү буенча бурычның булмавын раслаган, поручительнең исәп-хисаплары торышы турында салым органыннан, Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан һәм Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерүе фонды территориаль органыннан белешмәләр;

к) бу Тәртипнең 3.2 пунктындагы “а” пунктчасы нигезендә, хат белән мөрәҗәгать иткән елга кадәрге елда поручительнең бухгалтерия исәп-хисабының дөреслеге турында аудитор бәяләмәсе күчермәсе (Россия Федерациясе законы нигезендә еллык аудиторлык тикшерүе үтәргә тиешле юридик затлар өчен);

л) поручитель җитәкчесе имза салган һәм мөһере белән расланган, поручительнең чиста активлары исәпләмәсе;

Министрлык поручительне Бердәм дәүләт юридик затлар реестрына кертү фактын раслаган, шулай ук поручительнең үзгәртеп кору яки юкка чыгарылу процессында торуы (тормавы) турында, гарантка карата бөлгенлеккә төшү (банкротлык) эше буенча эш кузгатылган (кузгатылмаган) булуы турында мәгълүматларны раслаган документларны Федераль салым хезмәтеннән соратып алуга хокуклы.

3.3. Министрлыкка алынган поручитель документлары алынган көнне теркәлә.

3.4. Поручитель тарафыннан тапшырылган документлар бу Тәртипнең 3.2

пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры килмәгән очракта, Министрлык документлар теркәлгәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, аларны гарантка кире кайтара.

3.5. Поручитель тарафыннан тапшырылган документлар бу Тәртипнең 3.2 пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры килгән очракта, Министрлык аларны документлар теркәүгә алынганнан соң эш көннәрендә исәпләнелә торган 15 көн эчендә, гарантның бу Тәртипнең 3.1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен ачыклау өчен тикшерә һәм, бу Тәртипкә кушымта нигезендә, Поручительнең финанс хәлен бәяләү методикасы буенча, поручительнең финанс хәленә анализ ясый.

Бюджет кредитын кире кайтару буенча йөкләмәләрне үтәү буенча поручительләр булып торучы юридик затларның финанс хәлен анализлау түбәндәге очракта үткәрелмәскә мөмкин: әлеге юридик затлар алучыга бюджет кредитын бирү турында карар кабул итү датасына “Фитч-Рейтингс” (Fitch Ratings) яки “Стандарт энд Пурс” (Standard & Poor's) рейтинг агентлыклары классификациясе буенча “ВВ-“ дәрәҗәсеннән түбән булмаган рейтингка яисә “Мудис Инвесторс Сервис” (Moody'sInvestors Service) рейтинг агентлыгы классификациясе буенча “Ва3” күрсәткеченнән түбән булмаган рейтингка ия булганда (интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган сайтларында рейтинг агентлыкларының рәсми мәгълүматлары).

Министрлык документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча алучы йөкләмәләрен тәэмин итүгә поручительлекне кабул итеп алу мөмкинлеге (кабул итүдән баш тарту) турында бәяләмә әзерли, поручительгә бу хакта бәяләмә әзерләнгәннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча язмача хәбәр ителә.

Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган бюджет кредитларына банк гарантиясенең, поручительлекнең ышанычлылыгын (ликвидлыгын) бәяләү тәртибенә кушымта

## Поручительнең финанс хәлен бәяләү методикасы

1.1. Поручительнең финанс хәлен бәяләү өчен база финанс индикаторларының өч төркеме кулланыла:

ликвидлылык коэффициентлары;

үзенең һәм заем средстволарының нисбәте коэффициенты;

рентабельлелек күрсәткече.

1.2. Түбәндәге мәгълүматлар нигезендә исәп-хисап хәл ителә:

Форма № 1 (бухгалтерия балансы);

Форма № 2 (финанс нәтиҗәләре турында хисап).

2. Ликвидлылык коэффициенты

2.1. Ликвидлылык коэффициентлары төркеме өч күрсәткечтән тора:

абсолют ликвидлылык коэффициенты;

тиз ликвидлылык коэффициенты;

агымдагы ликвидлылык коэффициенты.

2.2. К1 абсолют ликвидлылык коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнелә:

$$K\,1 = \frac{ден.\,средства(1250) + кр.\,фин\,вложения(1240)}{кр.\,обязательства(1500 - 1530)}$$

монда:

акча средстволары – кассадагы һәм расчет счетындагы акча средстволары (балансның № 1250 юлы);

кыска сроклы финанс салулар – компаниянең хисап чорының азагына тупланган кыска сроклы финанс салулары (акцияләр, вексельләр, облигацияләр, бирелгән заемнар һ.б.) суммасы. Аларга әйләнештә булу (түләү) срогы хисап датасыннан соң яки операцион циклдан соң 12 айдан артмаган, срок 12 айдан күбрәк булганда (балансның № 1240 юлы), финанс салулар керә;

кыска сроклы йөкләмәләр – оешманың хисап датасыннан соң 12 айдан кимрәк түләү срогы белән кыска сроклы финанс йөкләмәләре. Балансының V бүлеге (№1500 юл) һәм булачак чорларның керемнәре (№ 1530 юл) йомгагы

аермасы буларак исәпләнелә.

2.3. тиз ликвидлылык коэффициенты акча средстволарын хуҗалык әйләнешеннән оператив төстә чыгаруга һәм тиешле финанс йөкләмәләрен түләүгә сәләтне күрсәтә. Күрсәткеч түбәндәге формула буенча билгеләнелә.

$$K2 = \frac{кр.деб.задолженность + кр.фин\,вложения(1240) + ден.средства(1250)}{кр.обязательства(1500-1530)},$$

Биредә:

кр.дебиторлык бурычы – ел дәвамында түләү көтелә торган дебиторлык бурычы;

кыска сроклы финанс салулар – компаниянең хисап чорының азагына тупланган кыска сроклы финанс салулары (акцияләр, вексельләр, облигацияләр, бирелгән заемнар һ.б.) суммасы. Аларга әйләнештә булу (түләү) срогы хисап датасыннан соң яки операцион циклдан соң 12 айдан артмаган, срок 12 айдан күбрәк булганда (балансның № 1240 юлы), финанс салулар керә:

акча средстволары – кассадагы һәм расчет счетындагы акча средстволары (балансның № 1250 юлы);

кыска сроклы йөкләмәләр – оешманың хисап датасыннан соң 12 айдан кимрәк түләү срогы белән кыска сроклы финанс йөкләмәләре. Балансының V бүлеге (№1500 юл) һәм булачак чорларның керемнәре (№ 1530 юл) йомгагы аермасы буларак исәпләнелә.

2.4. $K3$ агымдагы ликвидлылык коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнелә:

$$K3 = \frac{оборотные\ активы(1200)}{кр.обязательства(1500-1530)},$$

биредә:

әйләнештәге активлар – әйләнештәге активлар (балансның №1200 юлы);

кыска сроклы йөкләмәләр – оешманың хисап датасыннан соң 12 айдан кимрәк түләү срогы белән кыска сроклы финанс йөкләмәләре. Балансының V бүлеге (№1500 юл) һәм булачак чорларның керемнәре (№ 1530 юл) йомгагы аермасы буларак исәпләнелә.биредә:

әйләнештәге активлар – әйләнештәге активлар (балансның №1200 юлы);

кыска сроклы йөкләмәләр – оешманың хисап датасыннан соң 12 айдан кимрәк түләү срогы белән кыска сроклы финанс йөкләмәләре. Балансының V бүлеге (№1500 юл) һәм булачак чорларның керемнәре (№ 1530 юл) йомгагы аермасы буларак исәпләнелә.

## 3. Үзенең һәм заем средстволарының нисбәте коэффициенты

3.1. $K4$ үзенең һәм заем средстволарының нисбәте коэффициенты түбәндәге формала буенча билгеләнелә:

$$K4 = \frac{собственный\ капитал(1300)}{заемный\ капитал(1500+1400-1530)},$$

биредә:

үз капиталы – үз капиталы һәм резервлары (баланснының № 1300 юлы);

заем капиталы – финанс йөкләмәләре. Булачак чорлар керемнәреннән (баланснының №1530 юлы) тыш, кыска сроклы һәм озак сроклы йөкләмәләр (баланснының №1500 һәм № 1400 юллары) суммасы буларак исәпләнелә.

4. Рентабельлелек күрсәткече

4.1. $K5$ рентабельлелек күрсәткечен исәпләү тәртибе сәүдә предприятиеләре һәм башка тармаклар предприятиеләре булып торучы поручительләр өчен аерым билгеләнелә.

4.2. Рентабельлелек күрсәткече сәүдә предприятиеләре булып торучы поручительләр өчен түбәндәге формула буенча билгеләнелә:

$$K5 = \frac{прибыль\ от\ продаж(2200)}{валовая\ прибыль(2100)},$$

биредә:

сатудан табыш – продукция сатудан табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның №2200 юлы);

тулаем табыш – тулаем табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның № 2100 юлы).

4.3. Рентабельлелек күрсәткече башка тармаклар предприятиеләре булып торучы поручительләр өчен түбәндәге формула буенча билгеләнелә:

$$K5 = \frac{прибыль\ от\ продаж(2200)}{выручка(2110)},$$

биредә:

сатудан табыш – продукция сатудан табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның № 2200 юлы);

керем – керем (финанс нәтиҗәләре турында хисапның № 2110 юлы).

5. Финанс хәлен бәяләү

5.1. Һәр база индикаторы өчен иң яхшы һәм иң начар чик күрсәткечләре билгеләнелә.

5.2.Килеп чыккан күрсәткеч һәм һәр күрсәткеч өчен чик күрсәткечләр нигезендә өч категорияләрдән берсе билгеләнелә. Күрсәткечләрнең чик күрсәткечләре һәм, күрсәткечләрнең факттагы күрсәткечләренә бәйле рәвештә, категорияләрне сайлап алу кагыйдәсе 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица. Күрсәткечләрнең чик күрсәткечләре һәм, күрсәткечләрнең факттагы күрсәткечләренә бәйле рәвештә, категорияләрне сайлап алу

| Коэффициентлар | 1 категория (яхшы күрсәткеч) | 2 категория (канәгатьләнерлек күрсәткеч) | 3 категория (канәгатьләндерми торган күрсәткеч) |
|---|---|---|---|
| $К_1$ | 0,2 артыграк | 0,1 - 0,2 | 0.1 кимрәк |
| $К_2$ | 0,8 артыграк | 0,5 - 0,8 | 0.5 кимрәк |
| $К_3$ | 2,0 артыграк | 1,0 - 2,0 | 1.0 кимрәк |
| $К_4$ | | | |
| предприятия торговли | 0,6 артыграк | 0,4 - 0,6 | 0.4 кимрәк |
| предприятия других отраслей | 1,0 артыграк | 0,7 - 1,0 | 0.7 кимрәк |
| $К_5$ | 0,15 артыграк | 0,0 - 0,15 | 0.0 кимрәк (рентабельсез.) |

5.3. Җыелма бәя (S) түбәндәге формула буенча билгеләнелә:

$S$ = $Вес_1$ х $Категория_1$ + $Вес_2$ х $Категория_2$ + $Вес_3$ х $Категория_3$ + $Вес_4$ х $Категория_4$ + $Вес_5$ х $Категория_5$,

Биредә:

$Вес^i$ _ җыелма бәядә Кi саллылыгы күрсәткече, i= 1, 2,3,4 яки 5.

Саллылык күрсәткечләре 2 нче таблицада китерелгән.

i категориясе – Кi күрсәткеченә туры килә торган категория.

i категориясе = 1,2 яки 3.

2 нче таблица. Җыелма бәяне исәпләгәндә кулланыла торган күрсәткечләрнең саллылыгы

| Күрсәткеч | Күрсәткечнең саллылыгы |
|---|---|
| К1 абсолют ликвидлылык коэффициенты | 0,11 |
| К2 тиз ликвидлылык коэффициенты | 0,05 |
| К3 агымдагы ликвидлылык коэффициенты | 0,42 |
| К4 үзенең һәм заем средстволарының нисбәте | 0,21 |
| К5 рентабельлелек коэффициенты | 0,21 |

5.4. Поручительнең финанс хәленең җыелма бәя күрсәткече нигезендә:

җыелма бәя күрсәткече 1,5 тән артмаган очракта әйбәт булып тора;

җыелма бәя күрсәткече 1,05 тән зуррак булып, 2,4 тән артмаган очракта канәгатьләнерлек булып тора;

җыелма бәя күрсәткече 2,4 тән арткан очракта, канәгатьләнмәслек булып тора;

поручительнең чиста активлары күләме бирелә торган бюджет кредитыннан өч тапкырдан зуррак суммадан кимрәк булмаска тиеш.